**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЛАИШЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ СРЕДНЕДЕВЯТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА ДЕВЯТОВО АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422614 с.Среднее Девятово
ул. Сергеева, д.9
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

422614 а.Урта Девятово
Сергеев урамы, 9 нчы йорт,
тел: 8-(84378)-3-41-11
факс: 8-(84378)-3-41-11
Sdev.La@tatar.ru

2020елның 18 ноябре 42 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге Смолдеярово торак пункты гражданнары җыены карары**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авыл җирлеге Смолдеярово торак пункты гражданнары җыены карар кабул итте:

1. Лаеш муниципаль районының Урта Девятово авылҗирлеге Смолдеярово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда үзара салым чараларын 500 сум күләмендә кертергә, моңа балачактан көндезге формада белем алучы студентлар һәм инвалидлар керми.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә.:

-Смолдеярово торак пунктын су белән тәэмин итү системаларын реконструкцияләү һәм карап тоту (Үзәк ур.).

3. Әлеге карарны Урта Девятово авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Урта Девятово авылҗирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: ____________ О.Н.Чумарова

Урта Девятово авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ____________ О.Н.Чумарова